ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

***Постановление*** ***Карар***

____________________________ **Чистай шәһәре** **№** ________________

“2019-2021 елларга Татарстан республикасы
Чистай муниципаль районында
медицина кадрларын беркетү
һәм аларны торак белән тәэмин итү”
муниципаль программасын
Раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Уставы белән, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**Карар бирә:**

1.“2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү” муниципаль программасын кушымта нигзендә расларга.

2. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г. Ю. Задворновага йөкләргә.

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Башкарма комитетның
2019 елның __ октябрендәге
_____ номерлы Карарына
Кушымта

“2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү”
Муниципаль программасы

Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның җаваплы башкаручысы | - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программаны башкаручылар | - башкаручылар юк |
| Программада катнашучылар | - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программа ярдәмче программалары | - ярдәмче программалар юк |
| Программаның максаты | - муниципаль район территориясендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыру |
| Программаның бурычлары | - сәламәтлек саклау учреждениеләре ихтыяҗлары нигезендә, квалификацияле табиб-белгечләрне җәлеп итү өчен шартлар тудыру һәм беркетү;<br>- сәламәтлек саклау учреждениеләрен югары квалификацияле табиблык кадрлары белән тәэмин итү |
| Программаның күрсәткечләре (индикаторлары) | - торак бинаны яллау (арендалау) буенча чыгымнарны компенсацияләүгә бирелгән табиб-белгечләр саны-16 кеше. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | -2019 -2021 еллар:<br>1 нче этап – 2019 ел;<br>2 нче этап – 2020 ел,<br>3 нче этап – 2021 ел. |
| Программаның бюджет ассигнованиеләре күләме | Муниципаль район бюджеты, барлыгы: 1 134 000 сум,<br>шул исәптән: 2019 ел – 42 000 сум,<br>2020 ел – 420 000 сум,<br>2021 ел – 672 000 сум. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре | - сәламәтлек саклау оешмаларында квалификацияле табиб-белгечләрне беркетү;<br>- сәламәтлек саклау учреждениеләренең табиб кадрлары белән тәэмин ителешен арттыру;<br>- халыкка медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын һәм һәркем өчен үтемлелеген арттыру. |

## 1. Программаны тормышка ашыру өлкәсенең гомуми характеристикасы.

Сәламәтлек саклау өлкәсендә халыкның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга, гомер озынлыгын арттыруга юнәлдерелгән муниципаль сәясәтне алга таба камилләштерү - Чистай муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып тора.

Сәламәтлек саклау системасының сыйфаты күп факторларга бәйле: матди-техник базаның торышы, сәламәтлек саклау учреждениеләре эшчәнлегенең финанс-икътисадый шартлары, ләкин беренче чиратта белгечләрнең туплануы, һөнәри әзерлеге һәм квалификациясе дәрәҗәсе белән билгеләнә.

Муниципаль районда сәламәтлек саклау учреждениеләренең матди-техник базасын яхшыртуга шактый акча бүлеп бирелә, актив рәвештә яңа технологияләр кертелә, демографик күрсәткечләрнең уңай динамикасы күзәтелә.

Шул ук вакытта сәламәтлек саклау өлкәсендәге эшчәнлектә медицина хезмәткәрләренең дефициты арта баруы һәм аларның сәламәтлек саклау учреждениеләрендә кимүе тискәре яктан җитди йогынты ясый. Бу инде хәзер үк түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең үтемлелеге һәм сыйфаты кимүгә, шулай ук медицина ярдәме стандартларын һәм медицина ярдәме күрсәтү тәртибен үтәү мөмкин булмавына китерә. Бу хәл бигрәк тә авыл җирлегендә ачык сизелә.

Үз торагын сатып алу мөмкинлеге булмау - муниципаль районның сәламәтлек саклау өлкәсеннән квалификацияле кадрларның китүенә һәм эш урыннарын алыштыруга җитди сәбәп булып тора.

РФ законнарының үзгәрүен, социаль-икътисади вәзгыятьне тотрыкландыруны исәпкә алып, сәламәтлек саклау өлкәсендә өстенлекле милли проектны тормышка ашыруга бәйле рәвештә, районның сәламәтлек саклау системасын радикаль яңарту зарурлыгы туды. Сәламәтлек саклау өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган чаралар сәламәтлек саклау оешмаларында медицина хезмәткәрләрен җәлеп итәргә һәм беркетергә мөмкинлек бирә, әмма кадрлар проблемасын кардиналь рәвештә хәл итеп булмый.

Программа - максатчан метод программа чараларын тормышка ашыру өчен җирле бюджет акчаларын җәлеп итәргә, финанс ресурсларыннан нәтиҗәлерәк файдаланырга, билгеләнгән бурычларны хәл итүгә юнәлдерергә, шулай ук үткәрелә торган чаралар һәм аларны үтәү нәтиҗәләре арасында үзара бәйләнеш тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. Программада куелган бурычларны хәл итүдә программа-максатчан методны куллану - билгеле бер тәвәккәллек таләп итә. Программаны тормышка ашыру барышында торак базарында, шулай ук торак төзелеше тармагында, финанс-икътисади үзгәрешләр аркасында билгеләнгән нәтиҗәгә ирешү барышында тайпылышлар булырга мөмкин.

**2. Программаны тормышка ашыру өлкәсендә муниципаль сәясәт приоритетлары.**

Тәкъдим ителгән Программа сәламәтлек саклау системасының нәтиҗәлелеген арттыру өлешендә Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә туры килә.

Программа сәламәтлек саклау оешмаларының медицина хезмәткәрләре белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителмәү проблемасын хәл итүгә юнәлдереләчәк.

Табиб-белгечләргә ярдәм итү, торак шартларын яхшырту, Чистай муниципаль районы торак сәясәтенең мөһим юнәлеше булып тора.

Программаның максаты - халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыру.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

- сәламәтлек саклау оешмаларының ихтыяҗлары нигезендә, квалификацияле табиб-белгечләрне (алга таба – табиб-белгечләр) җәлеп итү өчен шартлар тудыру һәм беркетү;

- сәламәтлек саклау учреждениеләрен югары квалификацияле табиблык кадрлары белән тәэмин итү;

Программаны тормышка ашыруның төп принциплары булып тора:

- программада катнашу ирекле;

- программаны гамәлгә ашыру срогына торак урынын найм (аренда) түләү чыгымнарын компенсацияләү хокукын гамәлгә ашыру мөмкинлеге.

Программаны тормышка ашыру вакыты: 2019-2022 еллар.

Программаны тормышка ашыру этаплары:

1 нче этап: 2019 ел – программада катнашучылар составына 4 табиб-белгечне кертү; 4 табиб-белгечкә торак урыны наемга (аренда) түләү чыгымнарын компенсацияләүне бирү;

2 нче этап: 2020 ел – программада катнашучылар составына 6 табиб-белгечне кертү; 6 табиб-белгечкә торак урыны наемга (аренда) түләү чыгымнарын компенсацияләү бирү;

3 нче этап: 2021 ел – программада катнашучылар составына 6 табиб-белгечне кертү; 6 табиб-белгечкә торак урыны наемга (аренда) түләү чыгымнарын компенсацияләү бирү.

**3. Муниципаль программаның күрсәткечләре (индикаторлары).**

Программа күрсәткечләре (ндикаторлары) программаны гамәлгә ашыру еллары буенча бүленеп 1 нче таблицада күрсәтелгән.

**4. Программаны тормышка ашыруның төп чаралары һәм механизмы.**

Программа түбәндәге төп чараларны үткәрү юлы белән тормышка ашырыла (2 нче кушымта):

- программада катнашучылар составына кертелгән табиб-белгечләрне исәпкә алу;

- торак урыны наемга (аренда) түләү буенча чыгымнарга компенсацияләр бирү.

Программаны тормышка ашыру механизмы торак урынын наемга (аренда) түләү чыгымнарын компенсацияләү юлы аша торак шартларын яхшыртуда табиб-белгечләргә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән.

Җирле бюджет акчалары исәбеннән социаль ярдәм чаралары күрсәтелә:

- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә 5 календарь ел эчендә яшәү урыны буенча теркәлмәгән “Чистай үзәк район хастаханәсе” ДАССО белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы табиб-белгечләргә, шулай ук табиб-белгеч һәм аның гаилә әгъзаларының Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә урнашкан торак урыннар милкендә булмаган очракта.

Табиб-белгечләргә торак урыны наемга (аренда) түләү буенча компенсация бирү турындагы карар календарь елга кабул ителә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты һәм табиб тарафыннан төзелә торган килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

Табиб-белгеч үтенеченә кушымта итеп бирелә:

- программада катнашучының һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның күчермәләре (паспорт, яки аны алмаштыручы башка документ);

- “Чистай үзәк район хастаханәсе” ДАССО белән хезмәт мөнәсәбәтләре булуны раслаучы документларның тиешле расланган күчермәләре;

- программада катнашучының гаилә мөнәсәбәтләрен раслаучы документларның күчермәләре (никахлашу турында таныклык, аерылышу турында таныклык, бала туу турында таныклык (бала);

- өй китабыннан өземтә яки финанс-шәхси счет, фатир картасы;

- программада катнашучыһәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыныннан файдалану хокукын раслый торган документлар.

**5. Муниципаль программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү.**

Чистай муниципаль районының программаны тормышка ашыру өчен каралган бюджет акчалары күләме барлыгы: 1 134 000 сум тәшкил итә.

шул исәптән: 2019 ел – 42 000 сум,
2020 ел – 420 000 сум,
2021 ел – 672 000 сум.

Программаны финанслау чыганагы - Чистай муниципаль районы бюджеты акчалары.

**4. Программаны тормышка ашырудан көтелгән нәтиҗәләр.**

Программа чараларын үтәү түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

- сәламәтлек саклау учреждениеләрендә квалификацияле табиб-белгечләрне беркетү;

- сәламәтлек саклау учреждениеләренең табиб кадрлары белән тәэмин ителешен арттыру;
- халыкка медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын һәм үтемлелеген арттырырга.

1 нче кушымта

“2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү
һәм аларны торак белән тәэмин итү”
Муниципаль программасы күрсәткечләре (индикаторлары) турында
Мәгълүмат

| N т/н | Күрсәткеч исеме (индикатор) | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең аңлатмасы (Индикаторы) | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2019 год | 2020 год | 2021 год |
| Муниципаль программа | | | | | |
| Төп чара 1. | | | | | |
| 1 | Торак урыныннары найм (аренда) түләү чыгымнарын компенсацияләнүче табиб-белгечләр саны (аена өч мең биш йөз сумнан да ким түгел) | кеше | 4 | 6 | 6 |

2 нче кушымта

“2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү”
Муниципаль программасының төп чаралар Исемлеге

| N т/н | Төп чараның исеме | Җаваплы башкаручы | Вакыт | | Планлаштырылган соңгы нәтиҗә (кыскача тасвирламасы) | Төп чараны тормышка ашыра алмау нәтиҗәләре | Муниципаль программаның күрсәткечләре (Индикаторлары) белән элемтә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | тормышка ашыра башлау вакыты | тормышка ашырып бетерү вакыты | | | |
| 1 | “Табиб-белгечләрнең торак урыныннарын найм (аренда) түләү чыгымнарын компенсацияләү(аена өч мең биш йөз сумнан да ким түгел)”- төп чара | Татарстан Республикасында Чистай муниципаль районы башкарма комитеты | 2019 ел | 2021 ел | Чараны тормышка ашыру - сәламәтлек саклау оешмаларында квалификацияле табиб-белгечләрне беркетергә мөмкинлек бирәчәк | Сәламәтлек саклау учреждениеләре нең квалификацияле кадрлар белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителмәве | Торак урыны наемга түләү чыгымнарын компенсацияләү бирелгән табиб-белгечләр саны |

3 нче кушымта

“2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү
һәм аларны торак белән тәэмин итү”
Муниципальной программасын
тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү

| № т/н | Чараның исеме | Чыгымнар исеме | Бюджет акчаларын баш бүлүче (җаваплы башкаручы) | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме (мең сум.) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2019-2021 еллар эчендә барлыгы | Шул исәптән еллар буенча: | | |
| | | | | | | 2019 | 2020 | 2021 |
| 1. | “Табиб-белгечләрнең торак урыныннарын найм (аренда) түләү чыгымнарын компенсацияләү(аена өч мең биш йөз сумнан да ким түгел)”- төп чара | | Татарстан Республикасында Чистай муниципаль районы башкарма комитеты | муниципаль район бюджеты | 1 134 000 сум | 42 000 сум | 420 000 сум | 672 000 сум |